ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.01.2022 ел Баулы шәһәре № 12

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль контроль өлкәсендәге кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалткан дип танырга:

- 2017 елның 27 апрелендәге «Баулы муниципаль районында сәүдә эшчәнлеге өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияне башкаруның административ регламентын раслау турында» 194 номерлы (2018 елның 6 июлендәге 266 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән);

- 2017 елның 26 июнендәге «Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкару буенча административ регламентын раслау турында» 261 номерлы;

- 2017 елның 21 августындагы «Баулы муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 336 номерлы (2018 елның 27 февралендәге 73 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән»;

- 2018 елның 18 сентябрендәге "Тикшерү кәгазьләренең (контроль сораулар исемлегенең) формаларын раслау турында" 376 номерлы”

- 2018 елның 31 июлендәге «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 296 номерлы (2019 елның 15 гыйнварындагы 4 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән);

- 2020 елның 28 февралендәге «Гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, Баулы муниципаль районы территориясендә тикшерүләр уздыруның административ регламентын раслау турында» 35 номерлы (2020 елның 09 сентябрендәге 217 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров